ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.03.2020 г. М ө с л и м № 161

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы белем бирү оешмаларына инвалидлар өчен уңайлы шартлар тудыру, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү Тәртибен раслау турында.**

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Инвалидлар хокуклары турында Конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә, инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының иҗтимагый Советы белән килештереп, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының белем бирү оешмаларына инвалидлар өчен уңайлы шартлар тудыру, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р.А. Ильясов**

Килешенгән:

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иҗтимагый Советы рәисе
__________________Р.З. Султанов

Расланган:

____________________ 20__ №______
«Мөслим муниципаль районы» Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән
________________ Р.А. Ильясов

---

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының мәгариф оешмаларыннан файдалана алуы өчен инвалидларга шартлар тудыру, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү Тәртибе.**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы белем бирү оешмалары җитәкчеләре, закон һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә, инвалидлар белем бирү оешмаларыннан файдалана алсын өчен түбәндәге шартлар тудыралар һәм тәэмин итәләр:

- объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;
- хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында, объект территориясе буенча мөстәкыйль, шул исәптән хезмәт күрсәтүче объект хезмәткәрләре ярдәмендә, хәрәкәт итү мөмкинлеге;
- объектка керү алдыннан транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү (шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, объект хезмәткәрләре ярдәме белән) мөмкинлеге;
- тотрыклы күрү функциясе бозылган инвалидларны озата бару һәм объект хезмәткәрләре ярдәмендә объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;
- инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында объект хезмәткәрләре ярдәмендә хәбәр итү;
- инвалидларга, хезмәт күрсәтү кагыйдәләре турында мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм, шул исәптән хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү һәм алар тарафыннан хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләр башкару турында ярдәм күрсәтү;
- психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе рекомендациясе яки инвалидны индивидуаль реабилитацияләү программасы нигезендә, белем бирү оешмасы тарафыннан тьютор хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итү;
- дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре, башка уку китаплары, шулай ук коллектив һәм индивидуаль файдалануга өйрәтүнең махсус техник чараларын бушлай бирү;
- инвалидларга, мәгариф оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан, мәгариф өлкәсендә хезмәтләр алырга һәм объектларны башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә кирәкле башка төрле ярдәм күрсәтү.